КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 8 июнь г.Казань № 360

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны социаль яклау органнары аша транспорт чаралары алган инвалидларга транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе буенча иминият премияләре компенсациясен түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны 2008 елда тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 27 март, 189 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 14 гыйнвар, 10/1 нче, 2009 ел, 24 декабрь, 880 нче, 2010 ел, 27 декабрь, 1122 нче, 2011 ел, 05 декабрь, 994 нче, 2012 ел, 11 декабрь, 1078 нче, 2013 ел, 10 декабрь, 964 нче, 2014 ел, 25 декабрь, 1027 нче, 2015 ел, 21 декабрь, 962 нче, 2016 ел, 21 декабрь, 963 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2008 елда» сүзләрен төшереп калдырыга, «Халыкны социаль яклау органнары аша транспорт чаралары алган инвалидларга, иминият премияләре компенсациясен» сүзләрен «Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә, аларга түләнгән иминият премиясе компенсациясен» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2008-2010 елларда халыкны социаль яклау органнары аша транспорт чаралары алган инвалидларга транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе буенча иминият премияләре компенсациясен түләүне финанслауга каралган акчаны бирү тәртибе турында» 2005 ел, 19 август, 528 нче карарын (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 ел, 24 декабрь, 923 нче карары редакциясендә)» сүзләрен «Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе буенча аларга түләнгән иминият премиясе

компенсациясен түләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субвенцияләр бирү тәртибе турында» 2005 ел, 19 август, 528 нче карарын» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2008 елда» сүзләрен төшереп калдырырга, «Халыкны социаль яклау органнары аша транспорт чаралары алган инвалидларга, иминият премияләре компенсациясен» сүзләрен «Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә, аларга түләнгән иминият премиясе компенсациясен» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Халыкны социаль яклау органнары аша транспорт чаралары алган инвалидларга транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе буенча иминият премияләре компенсациясен түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны 2008 елда тоту кагыйдәләрен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларга план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2016 ел, 21 декабрь, 963 нче карарына 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\360.docx